Республика Татарстан

СОВЕТ ШАРЛИАРЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Школьная, д. 57, д.Шарлиарема
423372
Телефон: 4-57-55

Татарстан Республикасы

САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШӘРЛӘРӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Мәктәп урамы, йорт 57, Шәрләрәмә авылы
423372
Телефон: 4-57-55

ОГРН 1121651003671 ИНН/КПП 1636007010/163601001 ОКТМО 92653482

**РЕШЕНИЕ** **№117** **КАРАР**

**25 ноябрь 2019 ел**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге бюджетыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында субсидияләр бирү кагыйдәләре турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы нигезендә Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге бюджетыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында субсидияләр бирү кагыйдәләрен расларга(кушымта № 1)

2. Әлеге карар нигезләмәләре 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджетлардан башлап бюджет төзегәндә, раслаганда һәм үтәлгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» PRAVO.TATARSTAN.RU («Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында) һәм «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Шәрләрәмә авыл җирлеге
Советы Рәисе: Н.Н. Хуҗина

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлеге Советының
2019 елның 25 " ноябре, № 117
карарына 1 нче кушымта

**Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге бюджетыннан Сарман муниципаль районы бюджетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килгән чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында субсидияләр бирү кагыйдәләре**

1.Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр Сарман муниципаль районы (Алга таба – район) бюджетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Сарман муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында бирелә (алга таба – субсидияләр).
2. Әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен баш бүлүче-Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге башкарма комитеты.
3. Субсидияләр Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге башкарма комитетына әлеге Кагыйдәләрнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга тиешле финанс елына бирелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.
4.Субсидияләр бирү шартлары булып тора:
район бюджетында (район бюджетының җыелма бюджет язмасы) районның чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булу (финанслашу максатларында аларны үтәү өчен кирәкле күләмдә субсидия бирелә), шул исәптән Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге бюджетыннан субсидияләр бирү планлаштырыла торган күләмне дә кертеп, аларны үтәү өчен кирәкле күләмдә.;
Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге бюджетыннан район бюджетына субсидияләр бирү турында килешү төзү (алга таба – килешү).
5. Килешүдә түбәндәге төп нигезләмәләр булырга тиеш:
а) субсидияләрнең максатчан билгеләнеше;
б) субсидия бирү шартлары;
в) субсидия бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;
г) субсидия күчерү графигы;
д) субсидия бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен тикшереп тору тәртибе;
е) финанс тәэминаты чыганагы субсидия булган чыгымнарны тормышка ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе.
6. Килешү Сарман муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе һәм авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан имзалана.
7. Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы карарына агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджет турында кертелгән очракта, килешүләргә тиешле финанс елында субсидия бирүгә бюджет ассигнованиеләре күләмнәрен төгәлләштерүне күздә тоткан үзгәрешләр кертелә.
8. Субсидия алу өчен район башкарма комитеты субсидия алуга гариза бирә.

9. Район бюджетына бирелә торган субсидия күләме субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләменнән чыгып билгеләнә, ул Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге бюджетының керем мөмкинлекләреннән, район бюджетының финанс ярдәме күрсәтүгә булган ихтыяҗының күләменнән чыгып билгеләнә.

10. Субсидияләр Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең территориаль органы исәбенә, килешүдә билгеләнгән срокларда, район бюджеты үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган исәп-хисап счетына күчерелә.

11. Субсидияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субсидияләр калдыгы Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә җирлек бюджеты керемэнә кире кайтарылырга тиеш.

12.Район тарафыннан субсидияләрне файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү килешүдә билгеләнгән һәм субсидия куллануның нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләренең фактта ирешелгән күрсәткечләре нигезендә Сарман муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан башкарыла.

13. Сарман муниципаль районының җирле үзидарә органнары финанс-бюджет палатасына район бюджеты чыгымнары турында хисап бирә.